РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы,ул. Ленина, 44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы,Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.kaenlinskoe-sp.ru

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

06.09.2021 ел

№ 21

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, субсидияләр бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясынигезендә, Каенлыавылҗирлеге Советы карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, бирелә торган субсидияләр күләмен исәпләү методикасын расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башлык Р.Р. Гарипов

Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының
2021 елның 6 сентябрендәге
21 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Совет «Каенлинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»

Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Каенлыавылҗирлегебюджетыннан Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы бюджетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, субсидияләр бирү кагыйдәләре

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлыавылҗирлеге (алга таба - җирлек) бюджетыннан Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы бюджетына (алга таба – район), җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, субсидияләр бирелә (алга таба – субсидияләр).

2.Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына күрсәтелгән максатларга бюджет турында җирлек Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең баш бүлүчесе булып, җирлеге башкарма комитеты тора.

4. Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидияләрне бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турында җирлек Советы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм тәртибе район Башкарма комитеты һәм җирлек башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) бирелә торган субсидия күләме, аны күчерү тәртибе, шартлары һәм сроклары;

г) субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләре (нәтиҗәләргә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр) кыйммәте;

д) субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләренә ирешү буенча йөкләмәләр;

е) күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең сыйфатына һәм һәркем өчен мөмкин булуына карата билгеләнгән таләпләрне үтәү буенча йөкләмәләр-муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашуга бирелә торган субсидиягә карата;

ж)аны финанслашу максатларында субсидия бирелә торган гавами-хокукый

бераемлекнең чыгым йөкләмәсен билгели торган хокукый акт реквизитлары;

з) аны финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе, шулай ук субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләре күрсәткеченә ирешү турында һәм капиталь төзелеш объектларын проектлау һәм (яки) төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементлары, техник яктан яңадан җиһазлау белән) чараларын башкару графигын үтәү турында;

и) килешүне үтәү (үтәүне координацияләү) һәм хисап бирү функцияләре йөкләнә торган җирле үзидарә органы күрсәтмәсе;

к) килешүдә каралган йөкләмәләрне гавами-хокукый берәмлек тарафыннан үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

л) горизонталь субсидияне кире кайтару буенча гавами-хокукый берәмлек йөкләмәләре һәм мондый йөкләмәләрнең җитү очраклары;

м) килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы;

н) килешүнең үз көченә керү тәртибе турында нигезләмә.

7. Килешү проектын әзерләү авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан район башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешүгә район Башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирлек башлыгы кул куя.

10. Субсидияләр җирлек башкарма комитеты тарафыннан район бюджетына килешүдә билгеләнгән срокларда җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетына күчерелә.

11. Субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә җирлек бюджеты керемен ә күчерелергә тиеш.

12. Субсидияләр бирү елыннан соң киләсе елның 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган субсидияләр калдыгы, агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, җирлек бюджеты керемен ә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын законнар нигезендә авыл җирлеге башкарма комитеты контрольдә тота.

Татарстан РеспубликасыТүбән Кама
муниципаль районы Каенлы авыл
җирлеге Советының
2021 елның 6 сентябрендәге
21 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, бирелә торган субсидияләр күләмен исәпләү методикасы

1. Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләме, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

S= (Д1+Д2) - (Р+С)

кайда:

S – Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләр күләме;

Д1 – Каенлы авыл җирлегенең Россия Федерациясе Бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә беркетелгән салым һәм салым булмаган керемнәре;

Д2 – Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан кире кайтарылмый торган керемнәр;

Р – Каенлы авыл җирлеге бюджетының Түбән Кама муниципаль районының берләштерелгән бюджетын формалаштыруга ярдәм төп алымнар нигезендә формалаштырылган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә чыгымнары;

С – Каенлы авыл җирлеге бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр.

2. Каенлы авыл җирлеге бюджетыннанТүбән Кама муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә торган субсидияләр исәпләү тәртибе.

Субсидия күләме, Каенлы авыл җирлеге чыгымнарын алып, Каенлы авыл җирлеге кереме буларак исәпләнә.